ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2024 с.Старое Дрожжаное № 470

«Балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенә Фәхретдинов Рифкать Минналим улы исемен бирү турында

1969 елда төзелгән «Балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең беренче директоры (1969-2001ел) Фәхретдинов Рифкать Минналим улы исемен мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2017 елның 31 гыйнварындагы 14/2 номерлы карары «Муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында», Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турындагы материалларны карау комиссиясе утырышының 2024 елның 11 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 1969 елда төзелгән «Балалар сәнгать мәктәбе» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенә беренче директор Фәхретдинов Рифкать Минналим улы исемен бирергә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе бинасында Фәхретдинов Рифкать Минналим улына Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мемориаль такта урнаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе директорына (Усманова Г.А.):

балалар сәнгать мәктәбе хезмәткәрләренең хезмәт кенәгәләренә учреждениенең исемен үзгәртү турында язма кертергә;

учреждениенең локаль хокукый актларын әлеге карарга туры китерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.Ф. Җәләловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов